Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№21 (72)
27 июнь 2013 ел

## • Вакыйгалар эзеннән

**КФУ**ның **КАБУЛ ИТҮ КОМИССИЯСЕ ЭШЛИ БАШЛАГАНГА БЕР АТНА УЗДЫ**. Шушы вакыт аралыгында абитуриентларны мәгълүматлаштыруга зур игътибар бирелде. Укырга керергә теләүчеләр һәм аларның әти-әниләре үзләренә кирәкле мәгълүматны Казан университеты сайтына кереп белә ала. Аннан тыш, моннан бер ел элек КФУ да call-үзәк үз эшчәнлеген башлап җибәргән иде. Әлеге үзәкнең төп максаты: абитуриентларга булдыра алганча күбрәк һәм төгәлрәк мәгълүмат бирү. **8 (843) 221-33-33** бердәм номерына шалтыратып, теләгән һәр кеше КФУга укырга керүгә багышланган сорауларын бирә ала. Әлеге **«КАЙНАР ЛИНИЯ»** эш көннәрендә 9-17 сәгатьләрдә эшли.

• • • •

19 июнь көнне КФУның Идел буе төбәкара квалификацияне арттыру үзәгендә чуваш теле һәм әдәбияты укытучылары өчен «**ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУГА ИННОВАЦИОН ЯКЫН КИЛҮ**» дигән темага семинар үтте. Ул филология фәннәре докторы, М.Р.Федотов ис. Чуваш дәүләт университетының чуваш теле белеме һәм көнчыгышны өйрәнү кафедрасы профессоры Галина Семенова катнашында узды.

• • • •

**КФУ ДЕЛЕГАЦИЯСЕ** 20-21 июнь көннәрендә «Россия төбәкләре – стабильләшүдән үсешкә» исеме белән Чувашиянең Чебоксар каласында узган **VI ИКЪТИСАДИ ФОРУМЫНДА КАТНАШТЫ**. Чара кысаларында «Биокуркынычсызлык: ветеринария медицинасы, авыл хуҗалыгы һәм әйләнә-тирәне саклауда инновацион технологияләр» технология платформасы утырышы узды.

• • • •

8-17 июнь көннәрендә Камбоджа Корольлегенең Сиемреап һәм Пномпень шәһәрләрендә ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы Комитеты тарафыннан үткәрелә торган **ЯШЬЛӘР ФОРУМЫ** булып узды. Россия һәм Татарстан данын анда КФУның Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара бағланышлар институтының 3 курс студенты **ФӘРИДӘ ЗАКИРОВА** яклады.

• • • •

22 июнь көнне КФУга Сингапур республикасының премьер-министр урынбасары – финанслар министры **ТАРМАН ШАНМУГАРАНТНАМ** җитәкчелегендә зур **ДЕЛЕГАЦИЯ КИЛДЕ**. Тарих музеенда булганнан соң, кунаклар ТРның мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Educare сингапур компаниясенең укытучы-мастерларнын укыту өчен булдырылган уртак программалары белән танышты.

• • • •

23 июнь көнне КФУның Алабуга институты каршындагы мәйданда **УТ ЭСТАФЕТАСЫ БУЛДЫ** һәм **ФАКЕЛ КАБЫЗЫЛДЫ**. Универсиада утын 31 кеше, барлыгы 6600 метр озынлыктагы арада тотып йөгерде. Эстафета Үзәк стадионда тәмамланды һәм шунда ук шәһәр ут касәсе кабызылды. Тантаналы чара концерт программасы һәм Яшьләр көненә багышланган дискотека белән тәмамланды. Универсиада уты, шул рәвешле, республикабызның һәр районында «йөреп» чыгачак һәм 6 июль көнне Казанга килеп җитәчәк.

• • • •

24 июньдә **КФУ**га РФның Берләшкән Милләтләр Оешмасы системасында кеше хокуклары буенча өлкән киңәшче **РИШАРД КОМЕНДА** һәм өлкән киңәшченең офис программасы өчен җаваплы булган **РАШИД АЛУАШ ВИЗИТ ЯСАДЫ**. Кунаклар университет җитәкчелеге һәм юридик факультет вәкилләре белән очрашты. Анда юридик факультет базасында кеше хокуклары буенча магистрлык программаларын гамәлгә ашыруда КФУның да катнашачагы турында сөйләштеләр.

• • • •

28 июнь көнне КФУның Тарих музеенда Өзлексез белем бирү институтының Тренинг-үзәгендә ике еллык «Психология» курсларын тәмамлаучыларга **ДИПЛОМ ТАПШЫРУ ТАНТАНАСЫ БУЛАЧАК**. Музей хезмәткәрләре дипломчыларга бүләк тә әзерләгәннәр – «Казан университеты тарихы» экскурсиясе. Керү ирекле, һәр теләгән кеше әлеге тамашаны үз күзләре белән күрә ала.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Диана Поварова фотолары



# Универсиада алдыннан Олимпия көне

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

25 июнь көнне КФУда Халыкара Олимпия көнен зурлап уздырдылар. «Уникс»ның Кече залында үткән чарада мактаулы кунаклар, ТР Олимпия советы әгъзалары, Универсиада-2013тә катнашачак спортчылар, спорт ветераннары һәм КФУ студентлары катнашты.

Әлеге истәлекле дата Халыкара Олимпия комитеты тарафыннан 1967 елдан бирле 23 июньдә билгеләп үтелә. Универсиада башланырга санаулы көннәр калып барганда, Олимпия көнен нәкъ менә КФУда зурлап уздыру очраклы хәл түгел. Бу хакта КФУ ректоры Илшат Гафуров та билгеләп узды: «Без Универсиададан күп нәрсә алдык. Универсиада мирасы кысаларында төзелгән спорт объектларының күбесе югары уку йортлары кулланылышына тапшырылды. Шул исәптән, безнең университетка да. Универсиада авылы инде менә берничә ел буе университетыбызның структур бүлекчәсе булып тора: анда безнең студентлар яши», – диде ул. Илшат Гафуров һәр бишенче волонтерның КФУ студенты булуын да әйтеп китте. Ректор чарага җыелучыларны Олимпия көне белән котлап, аларга уңыш, саулык һәм җиңүләр теләде.

Чарада спорт ветераннары да катнашты. Алар арасында стендка ату буенча Лондон Олимпиадасында бронза медаль яулаган Василий Мосин, шул ук спорт төрендә Сиднейда көмеш олимпия медаленә лаек булган Светлана Демина, ватерпол буенча көмеш һәм бронза олимпия медальләре иясе Ирек Зиннуров, бокс буенча дөнья чемпионы исеменә ирешкән Айрат Хамматов һ.б. бар иде.

Россиянең Олимпия комитеты генераль сәркатибе, ТР Олимпия советы рәисе Марат Бариев та чарада катнашучыларны Олимпия көне белән тәбрикләде. «Безнең спортчылар Олимпия уеннарында актив катнаша килде. Инде 1952 елда ук 2 Казан спортчысы Советлар Союзы җыелма командасына эләгә. Шуннан бирле спортчыларыбыз һәрдаим илебез данын әлеге уеннарда яклап килә. Бу факт яшьләребезнең, тренерларыбызның сәләте турында сөйли. Тиздән Казанда Универсиада. Биредә утыручы студентларның күбесе азмы-күпме спорт белән кызыксынадыр. Ә менә Универсиададан соң спорт залы, стадион янынннан битараф кына узып китүче студентлар бөтенләй дә булмас, дип ышанам», – диде ул үз чыгышында.

Олимпия комитеты генераль сәркатибе сүзләренә караганда, башка ил турындагы тәэсирләрне иң беренче чиратта анда яшәүче халык тудыра. Бу уңайдан Марат Бариев казанлыларның кунакчыллыгына ышанычын белдерде.

Универсиадада Татарстан данын яклаячак яшь спортчыларга теләкләр рәвешендәге хат һәм кечкенә барс малае Юни уенчыгы тапшырылды. Чарада җиткерелгән изге теләкләр, бирелгән бүләк-символлар Уеннарда катнашучыларыбызга уңыш һәм бары тик җиңү китерер, дип ышанасы килә.

## • Ачыш

# КФУ Universka юл салды

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Шушы көннәрдә КФУда көтеп алынган зур вакыйга булды: В.П.Энгельгардт ис. Астрономия обсерваториясе базасында Планетарий ачылды. Ачылу тантанасында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, КФУ ректоры Илшат Гафуров, Россия финанс министры урынбасары, КФУның Кайгыртучанлык советы әгъзасы Алексей Лавров катнашты.

**Ахыры 2нче биттә.**



Диана Поварова фотосы

Уңыш сере

# «Иң яшь» студент

**Динара МИННЕКАЕВА**, хәбәрче

Җәй айлары күңелле, рәхәт чор булса да, үзенә күрә бер моңсу вакыты булып ала. Бу чор мәктәпләрдә, югары уку йортларында чыгарылыш кичәләренә туры килә. Башка еллардан аермалы буларак, быел бу хисләрне без алдан кичердек. Моңсу да, күңелле дә инде чыгарылыш кичәләре. Тыштан шат, чая йөзләрнең күңелләрендә нинди хисләр икәнен аңлау бер дә авыр түгел. Күбебез шул юлдан үткән кешеләр!

*Карыйм да, сокланам сиңа, халкым!*
*Шундый көчле, белемле, максатчан Син!*



Диана Поварова фотосы

Уку йортыбызның быелгы чыгарылыш кичәсе Казан федераль университеты тарихында аеруча истәлекле вакыйга булып калыр. Аның әһәмиятле булуы шунда: Алабуга институтын быел илебезнең иң өлкән студенты – 86 яшьлек Габдулла абый Галиев тәмамлады. Укып бетерү бер шатлык булса, ректорыбыз Илшат Гафуров кулыннан диплом алу икенче зур бәхет булгандыр! Габдулла абыйга карата булган горурлык хисләремне һич кенә дә яшереп кала алмыйм. Ул – минем якташым!

Габдулла абыйның балачагына артык тукталып тормасам да, аның ничек үткәнен күз алдына китерерсез. Бик авыр чорга туры килә ул. 1943 елда җидееллык мәктәпне тәмамлый да эшкә керешә. Илебездә барган дәһшәтле сугыш алар гаиләсен дә читләтеп узмый. Әтиләре сугыш кырында батырларча һәлак була. Ялгыз әнигә булышу, хуҗалыкны алып бару, балалар кулына кала. Тормышның ачысын да, төчесен дә татыган Габдулла абый сынмый-сыгылмый. Максатчанлыгы, үҗәтлеге ташып торган егет 1952-1955 елларда Алабугада медицина училищесын тәмамлый. Шул көннән башлап, лаеклы ялга чыкканчы, туган авылы – Әгерҗе районы Кырынды авылында фельдшер булып эшли. Кечкенә вакытта Габдулла абый турында әбиемнәр сөйләгән сүзләр әле дә хәтеремдә. «Без бер табибка да бармыйбыз. Безнең үз Габдуллабыз бар. Йомшак куллы, тәмле телле, киң йөрәкле ул», – дип гел сөйлиләр иде. Мин Габдулла абыйның шул вакытта ук «Доктор Айболит» итеп күз алдына китерә һәм гел аны күрү хыялы белән яши идем. Районыбызның хөрмәтле шәхесе шул ул!

Габдулла абый гомер буе югары белем алу турында хыялланып яши. Үзлектән дә күп укый, белем эсти. Табиб булуына карамастан, язучылык белән кызыксынып китә. «Нидер җитми кебек тоелды. Кемнән ким соң әле мин, дип уйладым да укырга керергә булдым. Тормыш иптәшем Тәскирә (бакый дөньяга күчкәненә – ике ел, авт.) дә зур йогынты ясады. Ул вакытта ректор булып Айдар Мансур улы Кәлимуллин (хәзер Педагогика һәм психология институты директоры, авт.) иде. Бик шаяртырга ярата торган кеше. Шулчак безгә: «Әби, бабаеңны кертәбез инде. Укып та чыгар, ләкин монда кызлар бик күп. Бабайсыз калырмын, дип курыкмыйсыңмы соң?» – диде. Шулай итеп мин студент булып куйдым», – дип искә ала ул көннәрне Габдулла абый. Алабуга шәһәре безнең район өчен уңайлы якта урнашмаган. Йөз чакрымнан артык юлны үз машинаң белән бик җиңел генә узып була, ләкин Габдулла абый яңгырлы көзләрдә, кышкы салкыннарда юлында очраган машиналарга берничә тапкыр күчеп утырып йөрергә мәҗбүр була. Бик сабыр холыклы булса да, әллә юл газабы, әллә кешеләрнең: «Ник кирәк инде сиңа ул уку?» – дигән сүзләре аны кире уйларга мәҗбүр итә. Ул яңадан ректор янына керә. Айдар Кәлимуллин аңа «укырга ирекле йөрү» хокукы бирә. Укытучылар да бу фикер белән килешә.

Һәркемгә үрнәк студент диплом темасының да җиңелен генә сайлап алмый. Шулай ук якташыбыз, драматург Юныс Әминев иҗатын тикшерә. Диплом темасы: «Ю.Әминев иҗаты. Образлар системасы, стиль үзенчәлекләре» дип атала. Теманы тиешле дәрәҗәдә ачу, анализлау өчен, ул аның биш әсәрен ала. Диплом җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты Фәридә Имаметдин кызы Гобәйдуллина билгеләнә. Әйтергә кирәк, эшне тиешле дәрәҗәгә җиткерү өчен, җитәкче дә күп көч куя. «Юныс белән без бик яхшы танышлар идек. Аның иҗатын бик хөрмәт итәм. Теле дә бик үзенчәлекле. Безнең район диалекты ярылып ята. Үзем дә иҗатымның башлангыч чорында пьесалар яздым. Аларны үзебезнең театрлар да куйды. Ике әсәремне Минзәлә театры сәхнәләштерде. Хәтердә: беренче пьесамны язгач, Юныс Әминев янына киттем. Танышып чыккач, кире борып җибәрмәде, киңәшләрен бирде. Ләкин мин ныклап прозага күчтем», – ди Габдулла абый. Аның үз стиле, үз теле бар, иң мөһиме: ул үз укучысын булдырган әдип, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Бүген Габдулла абый тыныч кына туган авылында гомер кичереп ята. Алдагы планнары турында сорашкач та, ул: «Мин хәзер укытучы булып эшли алмам инде. Төп эшем язу булыр. Язучы белән укытучыны аерып карый алмыйм мин. Алар – бербөтен. Без дә китаплар язабыз, балалар белән очрашабыз. Иҗатыбыз аша аларга тәрбия бирергә тырышабыз», – диде. Габдулла абыйның яшьләргә дә теләкләре изге: «Сабыр булыгыз! Уку бер дә җиңел түгел, ихтыяр көче, нык сәламәтлек кирәк. Аллаһы Тәгалә ярдәменнән ташламасын. Тырышыгыз, аның нәтиҗәсе булмый калмый!» – диде.

Габдулла абыйга сокланмыйча мөмкин түгел. Аңа алдагы тормышында тыныч, имин көннәр, саулык телибез. Күз тимәсен Сезгә, Габдулла абый. Безнең өчен үрнәк булып, озак еллар яшәсәгез иде!

Ачыш

# КФУ Universka юл салды

Башы 1нче биттә.

Астропаркның бер өлеше булган әлеге планетарий нигезенә беренче таш моннан ике ел элек – 2011 елның 22 августында салынган иде. Планетарий ачылу һәм ерак космосны өйрәнү өчен, КФУ каршындагы космик тикшеренүләр һәм технологияләр Үзәген булдыруда бер әһәмиятле этап булып тора.

КФУ ректоры сүзләренә караганда, планетарийны төзү чорында 9 илдәге 22 планетарий тәҗрибәсе өйрәнелгән. **И. Гафуров** проектның инвесторы «АК БАРС» БАНК ААҖ, генераль подрядчысы «Ак Барс Строй» оешмасы һәм республика җитәкчелегенә рәхмәтен белдерде. «Бу – Россиядәге университетлар составында эшләп килә торган бердәнбер планетарий һәм ул тулысы белән аның фәнни берләшмәсенә хезмәт итәчәк. Планетарий Россия Фәннәр академиясе һәм башка идарә тармаклары белән берлектә тормышка ашырыла торган фәнни, фәнни-гамәли программаларга да туры килеп тора, – дип белдерде ректор үз чыгышында. – Әлеге объект бүгенге укучыларга һәм студентларга космос, физика, химия, биологиягә таба юл ачар, илебездә фән дәрәҗәсенең үсүенә, белемнең әһәмиятен аңлауга китерер, дип уйлыйм».

**Рөстәм Миңнеханов**, үз чыгышында, федераль университет буенча планнарның зурдан булуы турында әйтте. Президент планетарий ачылышын әлеге планнарның чираттагы этабы рәвешендә бәяләде. «Безнең бу обсерватория гасырлык тарихка ия һәм бүген ул яңа сулыш ала. Биредә җитди фәнни база булдырылган, югары квалификацияле белгечләр әзерләнгән. Монда без саклап калырга теләгән һәм киләчәктә дә үсеш алырга тиешле ныклы фәнни нигез салынган», – диде ил башлыгы. Президент КФУ ректорына обсерваториягә алып бара торган юлларны сурәтләгән 1911 елгы тарихи документ тапшырды. Астрономия обсерваториясен заманча фәнни җиһаз белән тәэмин итүгә үз өлешен керткәне өчен, «Глобал Софт» оешмасы генераль директоры Илнат Хәйруллин Президентның рәхмәт хатына лаек булды.

КФУның Кайгыртучанлык советы әгъзасы, Россия финаслар министры урынбасары **А.Лавров** фикеренчә, КФУ Планетарие дөньядагы иң яхшы планетарийлар рәтендә. А.Лавров обсерватория үсешенә һәм яңа фәнни объектлар булдыруга зур өметләр баглавын белдереп: «Галәм латинча – Univers. Казанда уздырылачак дөньякүләм Универсиада алдыннан федераль университетыбызның Universka, Галәмгә тәрәзә ачуы бик шәп!» – диде.

Хәзерге вакытта планетарийда «Кара чоңгыллар», «Дарвин эволюциясе» һәм «Галактика үсеше» дип исемләнгән галәм турындагы кызыклы фильмнар карарга мөмкин. Фильмотека һәрдаим тулыландырылачак.

Яңа ачылган планетарийны һәм шуның белән беррәттән башка планета-йолдызларны күрергә теләүчеләрне сентябрьдән кабул итә башлаячаклар. Билет бәясе якынча 100-200 сум булыр дип көтелә.

Хезмәттәшлек

24 июнь көнне КФУга профессор, тарих фәннәре докторы, Ереван дәүләт университетының ректоры Арам Симонян җитәкчелегендәге делегация килде. Кунакларны ректор һәм университет җитәкчелеге каршы алды.

# Яңа дәрәҗәдәге элемтәләр

**Алинә САДЫЙКОВА**, хәбәрче



Диана Поварова фотосы

Делегация вәкилләре университет белән танышуны Тарих музееннан башлады. Анда аларга КФУның бай һәм кызыклы тарихы турында сөйләделәр, соңрак **Илшат Гафуров** уку йортыбызның хәзерге торышы, структурасы һәм юнәлеше турында мәгълүмат бирде.

**Арам Симонян**, үз чыгышында, үзе җитәкли торган университет һәм совет заманында булган, әмма бүгенге көндә өзелгән хезмәттәшлек элемтәләрен яңадан ялгау белән шөгыльләнүләре турында сөйләде: «Без хәзер күп кенә чит ил һәм Россия университетлары белән хезмәттәшлек итәбез. Бүген дә КФУ белән якынаю адымнары ясыйбыз. Безнең өчен бу иске элемтәләрне яңадан торгызу гына түгел, ә бәлки бу элемтәләрне яңа дәрәҗәдә, яңа университет белән урнаштыру ягыннан бик мөһим. КФУ – яңа структуралы, бөтен төрле югарылыктагы университетка әверелде».

Советлар союзы таркалганнан соң, Ереван дәүләт университетында да үзгәрешләр барлыкка килә. Шулай да алар үзләренең классик университет статусын саклап кала алганнар. «Безгә кырыс конкуренция шартларында эшләргә туры килә. Республикабыз зур түгел, шулай да бүгенге көндә анда 22 дәүләт һәм 32 шәхси югары уку йортлары исәпләнә. Бу кирәгеннән артык, дип саныйм», – диде ЕДУ ректоры. ЕДУ Армения республикасының иң зур университеты санала. Анда егерме меңгә якын студент гыйлем эсти, шуларның мең өч йөзе укытучылар икән. Биредәге бюджетның 28 процентын гына дәүләт финанслый, ә калган 72 процент акчаны университет түләүле уку, грантлар, фәнни-тикшерү эшләре алып бару ярдәмендә үзе таба.

Ике як та, университетлар турында билгеле бер күзаллау барлыкка килгәч, хезмәттәшлек җепләрен урнаштырырга кирәк, дигән фикергә килделәр һәм килешүгә кул куйдылар. Әлеге килешү буенча, студентлар һәм укытучылар алышу процессы, уртак проектлар, чаралар булдыру һәм, гомумән, академик эшчәнлекнең барлык юнәлешләрендә тыгыз хезмәттәшлек каралган. Физика өлкәсенә аеручы басым ясалачак.

**Галимнәребез**

# Аның үз йолдызлары бар

Бүген без сезне танылган астроном, үзенең гыйльми эшчәнлеге белән астрономия фәненең дөньякүләм үсешенә шактый зур өлеш керткән, аңа нәтиҗәле хезмәт күрсәткән һәм югары квалификацияле белгечләр хәзерләүдә, тәрбияләүдә дә күп көч сарыф иткән Шәүкәт Таип улы Хәбибуллин белән таныштырырбыз. Ул Казан университеты галимнәре арасында лаеклы урын алып тора.



Шәүкәт Хәбибуллин 1915 елның 25 гыйнварында Ташкент шәһәрендә дөньяга килә. Аның бабасы – китап басу остасы Шаһингәрәй Бикколов – Петербург Фәннәр Академиясе һәм Казан университеты типографияләрендә эшләгән. Шәүкәт Таип улы күп балалы гаиләдә беренче бала була һәм мөстәкыйль тормыш адымнарын да бик иртә башлый. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, ул комсомол чакыруы буенча, Ленинградка китә, биредә химик-лаборантлык курсларында укый һәм, курсларны тәмамлаганнан соң, Казахстанда төсле металлар һәм тимер чыганакларын эзләү буенча геологик эзләнүләр экспедицияләрендә эшли. Күрәсең, геологик эзләнү экспедипияләре дәверендә күзәтелгән Галәмнең төнге могҗизалары яшь Шәүкәтне геолог түгел, ә нәкъ менә Күк җисемнәрен тикшерү белгече – астроном булу теләген көчәйтә, аны Казан университетына алып килә. 1934 елны Ш.Хәбибуллин бу уку йортының астрономия бүлегенә кабул ителә. Һичшиксез, Ш.Хәбибуллинның профессор Д.Я.Мартынов белән очрашуы киләчәктә аның галим-астроном булып формалашуында гаять зур роль уйный.

Берничә үзгәрүчән йолдызның яктыручанлык кәкреләрен тезү һәм аларны тикшерү студент Ш.Хәбибуллинның беренче фәнни эше булып тора. Бу эшнең фәнни җитәкчесе Астрономия обсерваториясе директоры, профессор Д.Я.Мартынов студентның хезмәтеннән бик канәгать кала һәм Б.П.Энгельгардт ис. Астрономия обсерваториясендә төшерелгән фотопластинкаларда яңа үзгәрүчән йолдызларны табу мәсьәләсен аңа диплом эше итеп тәкъдим итә. Студент Ш.Хәбибуллин элек билгеле булмаган үзгәрүчән җиде йолдызны таба. Аңа аспирантурага керергә тәкъдим итәләр.

Аспирантурада укуның беренче елында ук, ул үзгәрүчән йолдызларга кагылышлы һәм 1940 елны Кояш тотылуны күзәтү нәтиҗәләренә багышланган өч фәнни хезмәт бастырып чыгара. 1941 елның 20 июнендә философия буенча кандидатлык имтиханын бирә, ә 22 июньдә Германия илебезгә каршы сугыш башлый. Сугыш башланып, биш көн дә үтми, Ш.Хәбибуллинны Кызыл Армия сафына алалар һәм, кыска сроклы хәрби курслар үткәннән соң, Мәскәү тирәсенә фронтка җибәрәләр. Шәүкәт Таип улы кече лейтенант дәрәҗәсендә рәхимсез сугыш эченә кереп китә һәм сугыш юлын Эльба елгасы янында майор дәрәҗәсендә тәмамлый. Бөек Ватан сугышы кырларында күрсәткән батырлыклары өчен Шәүкәт Таип улы 5 орден, 3 медаль белән бүләкләнә. Берлин операциясендә катнашкан һәм анда күрсәткән батырлыгын зурлап бирелгән Кызыл Байрак ордены һәм «Берлинны алган өчен» медале аның иң кадерле ядкәрләре була.

1946 елның язында Ш.Хәбибуллин Казан университеты каршындагы аспирантурага белем алуын дәвам итә, ә ике елдан соң безнең Галактика структурасын тикшерүгә багышланган кандидатлык диссертациясен яклый.

Казан университетында Шәүкәт Таип улы йолдызларны астрономик тикшерүне яңадан башлап җибәрә. Ул Галактика яссылыгыннан, Галактика үзәгеннән һәм антиүзәгеннән, Галактика радиусына перпендикуляр юнәлешләрдән төрле ераклыклардагы йолдызларның урнашу тыгызлыгын (таралуын) хисаплау ысулын куллана. Бу тикшеренүләр нәтиҗәсендә бик кызыклы мәгълүматлар ала, нәтиҗәләр ясый, яңа мәгълүматлар йолдызлар астрономиясе буенча дәреслекләргә кертелә.

Шәүкәт Таип улы обсерваториядә эшләү белән бер үк вакытта университетта астрономия кафедрасында да эшли. Студентларга көненә бишәр-алтышар лекция укый, Казаннан обсерваториягә кайтып, төннәрен йолдызлар күзәтә.

1975 елны Төньяк Кавказда, Ш.Хәбибуллинның тырышлыгы аркасында, Казан университетының Цейс-400 телескобы урнаштырылган күзәтү базасы барлыкка килә. Университет өчен яңа 1,5 метрлы телескоп төзүне оештырып җибәрүче дә ул була.

1960 елны университетның физика-математика факультетыннан физика һәм механика-математика факультетлары бүленеп чыгалар. Яңа оештырылган физика факультетының деканы итеп Шәүкәт Таип улы сайлап куела. Ш.Т.Хәбибуллин декан булган чорларда физика факультеты студентлар тормышының барлык өлкәләрендә дә лидерлыкны бирми. Бу факт аңарда яшьләрне аңлау, аларны оештыру сәләте гаять көчле булуын күрсәтә.

1965 елны Шәүкәт Таип улы университетның фәнни эш буенча проректоры итеп куела. Бу чорда университетта фәнни тикшеренү бүлеге оештырыла, фәннең перспектив юнәлешләре буенча өр-яңа лабораторияләр (бионика, микробиология лабораторияләре, Көньяк астрономия станциясе, хисаплау үзәге һ.б.) ачыла.

*Мәгълүмат «Мәшһүр татар галимнәре» китабыннан алынды*

**Сәяхәттән кайткач**

Себер бик күпләрне үзенең гүзәл табигате, салкын, ләкин саф һавасы, шифалы күлләре һәм, әлбәттә, озын юллар романтикасы белән тартып тора. Себерне бер күргән кеше аны мәңге онытачак түгел. «Июнь аенда Себергә китәм», – дигән хәбәремне ишеткәч, күпчелек дусларым да чикә тирәсендә бармакларын әйләндереп кенә күрсәттеләр. Эх, шул вакытта белсәләр иде ничек ялгышканнарын!

# Себер көндәлекләре яки Радлов эзләре буйлап

**Светлана ГЫЙЛӘҖЕВА,**
татар филологиясе бүлеге студенты

*31.05.2013*

Казан вокзалында үземнең университет галимнәре – профессор Ф.Й.Йосыпов, доцентлар О.Р.Хисамов, И.Г.Гомәров һәм курсташларым белән безне Новосибирск шәһәренә житкерәсе поездны көтәбез.

Менә инде йөрәк тәгәрмәчләр шавы белән бер ритмга тибә. Башта мең дә бер сорау... Уйларыңны тәртипкә китерер өчен ике чара бар: ялгызлык һәм озын юл. Ләкин бу очракта, ни гаҗәп, барган саен сораулар арта гына. Шундыйрак уйлар белән мин, бишектә чайкалган сыман, поезд тәгәрмәчләренең синхрон шавы астында йокыга талдым...

*02.06.2013*

Новосибирскига килеп төшкәндә, безнең өстә җиңел кием иде. Ә шәһәрдә +4 градус икән! Шәһәр халкы да безгә мәзәк итеп карый, кайберләре: «Сез кайсы илдән?» – дип тә сорыйлар. Әйе, 30 градуслы җылы Казаннан соң монда ияләшү бераз авыррак булыр... Хәер, татар кайда да югалмас!

Новосибирск өлкәсендә кунакларны каршы ала беләләр: кайнар ашлар, чәй, ә барыннан да кадерлерәге – җылы сүз һәм якты йөз. Шәһәрдәге мәчетне дә күрдек – ерак себер якларында да кардәшләребез үз динен югалтмыйча яши икән, дигән уй күңелләргә җылы өстәде. Россия Фәннәр Академиясенең себер филиалында булу бәхетенә ирештек! Бу шәһәрчекне Академгородок, дип йөртәләр. Чыннан да, бу – фән шәһәрчеге. Новосибирск шәһәре матур, чиста. Күпмедер дәрәҗәдә үзебезнең Казанны да хәтерләтә хәтта. Монда кире кайтмыйча булмас, ахры, дигән уйлар белән икенче көнне без инде Чаны районына юл тоттык.

*03.06.2013*

Бу район Новосибирскидан 500 чакрым ераклыкта урнашкан. Чаны районында Карачи дигән шифалы су бар икән. Минераль су җитештерү буенча да район өлкәдә алдынгы урынны алып тора. Хәтта краннан шул минераль су ага!

*04.06.2013*

Менә ул экспедициянең беренче көне! Өч меңнән артык чакрым араларны узып килүебезнең максаты! Юл буе Фәрит Йосыпович безгә Радловның ерак 1872 елда булган Себергә сәяхәте турында сөйләде. Яшь алман студентының ничек итеп үз күзләре белән бараба татарларын күрергә хыялланганы, Россиягә килеп, бик озак Себергә барырга рөхсәт ала алмавы, үз теләгенә ирешер өчен, алман гражданлыгыннан баш тартырга мәҗбүр булуы, ничек итеп кечкенә двуколкада кучер, Радлов үзе һәм сөйгәне – Паолинаның озын юлларны үтүләре, нәтиҗәдә – аның «Образцы народной литературы тюркских племен» дип аталган искиткеч хезмәте басылуы... Профессорыбыз бөек шәхес турында яңа фактлар гына түгел, ә киң бер дөнья ачты. Нинди бәхет – Радлов үзе йөргән җирләрдә менә инде 141 елдан соң без дә йөрибез!

Чортанлы зур авыл түгел, халкы бердәм, гади, аралашучан. Әйе, диалекталь үзенчәлекләр шактый, аңлап бетермәгән чакларда хөрмәтле укытучыларыбыз ярдәм итте. Әмма ул барыбер безнең татар теле. Татарстаннан ничә чакрым еракта булса да, татарлыгын югалтмаган халык, телен онытмаган, йолаларын ташламаган. Киләсе Белехта авылы шулай ук бик яхшы тәэсоратлар калдырды.

*07.06.2013*

Чаны районының тагын әле Аулкошкүл, Тармакүл, Аялу, Тебис авылларында булдык. Һәр авыл үзенең кунакчыллыгы, безгә һәм без башкарган эшкә карата хөрмәте белән күңелләребезгә хуш килде. Бик матур әңгәмәләр, яңа дуслар... Бу район турында без бары тик яхшы фикердә калдык.



*08.06.2013*

Кыштау районында ике татар авылы бар икән. Усмановка, Тарлар авыллары халкы шулай ук безнең белән бик теләп аралашты. Җирле халыкның диалектында хәзер инде үзебез дә рәхәтләнеп сөйләшә башладык. Халык исә таң калып: «Син парабыча кайан белмәк?» («Син барабача кайдан беләсең?») дип сорый. Без бары тик җилкәне генә сикертәбез: «Ә Казанда барысы да барабача белә», – имеш...

*09.06.2013*

Бүген без Венгер районының Воробьевка һәм Чаргар авылларында булдык. Үз итеп һәм яратып өлгергән Чаныда соңгы төн кунабыз. Иртәгә иртән Куйбышев шәһәренә китәсе. Күзгә йокы керми. Әллә артык сентименталь, әллә артык романтик – ни генә булса да аерылышуларны авыр кичерәм, ахыры.

*10-11.06.2013*

Куйбышев районының Омавыл, Аулшагыр, Яргөл авыллары. Кунакчыл, мөлаем халык та соң! Җырлап, биюләре генә ни тора?! Үз мәдәниятләрен саклап, горурланып яшиләр. Аларны күреп, күңел шатлана. «Шагырның суын эчкән кеше – кире кайта», – диделәр шагырлылар. Ышанасы килә.

*12.06.2013*

Һиһаять, Бараба. Аултантов һәм Бакчагөл авыллары. Нәкъ шушында тарих башлана да. Ә безнең экспедиция өчен – бу соңгы тукталыш. Иртәгә инде юлга чыгабыз. Бараба татарлары безгә инде хәзер китаптан гына түгел, ә якыннан таныш. Таныш һәм якын.

*13.06. 2013*

Бүген безнең кайтасы көн. Поезд шавы тагын колакта чыңлап тора. Бу юлы инде ул моңсу гына тимер рельстан тәгәрәгән кебек. Юлда дуслар белән кайту күңелле булса да, һәркемнең үзе генә белгән моңсу сере бар иде. Экспедиция да уңышлы гына үтте, хәйран материал да җыелды. Ә күңелнең бер өлеше Себердә калды. Күлләр, калын урманнар, барабалар, кунакчыл мөлаем татарлар ягын без озак сагыначакбыз, монда тагын бер кайту хыялы белән яшәрбез сыман.

Таныш бул!

# «Үз-үзеңә ышанмау – иң начар авыру»

**Ләйсән ГАЛИУЛЛИНА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Кеше еш кына зарланырга һәм «булдыра алмыйм» дип әйтергә ярата. Мин үзем дә күп кенә талантлы, әмма курку хисе аркасында үз хыялларына нокта куйган затларны беләм. Тик күптән түгел терәк-хәрәкәтләнү аппараты бозылган яшьләр арасында 5 тапкыр дөнья чемпионы, КФУның физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты студенты Александр Марков белән танышкач, кешедә чиксез мөмкинлекләр бар, аларны куллана белергә генә кирәк икәнлегенә инандым. Ә моны эшләргә ничек өйрәнергә дигән сорауга җавапны интервьюда таба аласыз.

**– Саша, нинди спорт төре белән шөгыльләнәсең?**

– Җиңел атлетика, спринт, 100, 200 метрлык дистанцияләргә йөгерү.

**– Синең физик мөмкинлекләрең чикле, бер кулың юк, ә бит, хәтта сау-сәламәт кешеләр дә спорт юлына басарга курка...**

– Үз үзеңә ышанмау – төрле авыруларга караганда да начаррак чир. Бөтен җиңүләр һәм җиңелүләр безнең башыбызда туа. Без көчле. Ә уңышсызлыклар - өскә таба бер баскыч, бәһасез тәҗрибә. Нәкъ менә алар безне алга таба барырга этәрергә тиеш. Иң мөһиме: моны аңлый белергә кирәк. Тормышта да бит тырыш, максатчан кешеләр бик зур уңышларга ирешә һәм хәтта кемнеңдер кумирларына әйләнә.

**– Кумирларга килсәк, спортта син кемнәрне үрнәк итеп карыйсың?**

– Кумирларым юк, әмма үрнәк алырдай кешеләр бар. Усейн Болт, спринтер, 100 һәм 200 метрлык дистанцияләргә йөгерүдә дөнья рекордсмены. Аның таланты бер кешене дә битараф калдыра алмый. Асафа Пауэллның исә йөгерү техникасы ошый. Оскар



Писториус үзенең максатчанлыгы белән шаккатыра. Күбесенчә 400 метрлык аралыкка йөгерә торган бу спортсмен-инвалид-ампутант. Андый кешеләргә, гадәттә, Олимпия уеннарында катнашу мөмкинлеге юк. Тик бу кеше әлеге уеннарда сау-сәламәт кешеләр белән беррәттән йөгерде һәм ярымфиналга кадәр барып җитте.

**– Синең дә, сәламәтлегең чикле булу аркасында, Казанда узачак җәйге бөтендөнья студентлар уеннарында катнашу мөмкинлегең юк. Бу факт борчымыймы?**

– Әлбәттә, туган ягыңда уздырылган шундый масштаблы вагыйгадан читтән каласы килми, әмма минем ул вакытта төрле стартлар күп булачак, шуңа күрә күңелсез уйларга бирелергә вакытым булмас. (*Г.Л. - елмая*).

**– Ә спорт белән үзең кайчан шөгыльләнә башладың?**

Балачактан ук мин бер урында утырырга яратмыйм. Мәктәптә укыганда, бөтен малайларга якын булган футбол, баскетбол, волейбол уйнадым. Ә менә җиңел атлетика игътибарымны 10 сыйныфта җәлеп итте. Гомумән, башта спортка яхшы физик формада булыр өчен килдем. Соңрак кына хобби, карьера дәрәҗәсенә үсте.

**– Профессиональ спортта яхшы тренердан башка ерак китеп булмый, ә син үзеңнең укытучың белән ничек таныштың?**

Безне язмыш очраштырды (*Г.Л. - елмая*). Беренче курс башында студентларны физик тәрбия дәресләрендә юнәлешләр буенча төркемнәргә бүлделәр. Җиңел атлетика белән шөгыльләнергә теләк белдердем. Барышников Алексей Святославович дигән тренер мине үз дәресләренә чакырды, шул вакыттан башлап, без бергә хезмәт куябыз да инде.

**– Ә бу вакыт аралыгында нинди уңышларга ирешелде?**

– Мин - терәк-хәрәкәтләнү аппараты бозылган яшьләр арасында спорт мастеры. Берничә тапкыр Россия беренчелекләрендә җиңдем, ике тапкыр Россия чемпионы булдым.

**– 21 яшьлек егет булсаң да, син инде шактый югары нәтиҗәләргә ирешә алгансың. Тагын нинди хыялларың бар?**

– Хыялланырга яратуның бернинди зыяны юк. Гомумән алганда, андый сәләт кешегә файда гына китерә. Әмма, тулаем алганда, тормышта минем максатлар һәм планнарым шактый күп.

**Без исә бу талантлы егет үз дигәненә ирешер дип уйлыйбыз. Һәм киләчәктә аңа бары тик уңышлар телибез!**

Сораштыру

# Ничек хәлләр, волонтер?

**Илмир ВӘЛИЕВ,** Гимнастика үзәге волонтеры

Фантазиягә бай, ихтыяр көче нык булган, эштән тәм табучы егетләр-кызлар тирә-юньдәгеләрдә, һичшиксез, соклану һәм хөрмәт хисе уятадыр. Универсиада 2013 волонтерлары менә нәкъ шундый!



КФУның матбугат үзәге

Бу чара уңаеннан мәркәзебезгә барлыгы 20000 волонтер киләчәк. Һәркайсыбыз үз функциябез өчен җаваплы һәм шуның буенча әзерлек уза. Универсиада вакытында бернинди дә аңлашылмаучанлыклар килеп чыкмасын өчен, гаять зур вакыйганы югары дәрәҗәдә үткәрү максатыннан, тренерлар безне эшнең бөтен нечкәлекләренә өйрәтә. Аккредитация узган волонтерлар буларак, без функциональ тренингларга йөрүне бу атнада ук башлап җибәрдек. Безнең өчен шулай ук, Универсиадага әзерләнү белән беррәттән, күңел ачу һәм спорт программалары да оештырыла. УНИКС спорт залы бер дә буш тормый: рәхәтләнеп волейбол, баскетбол һәм башка спорт уеннары уйныйбыз. Этнографик, геология музейларына экскурсиягә бардык, Казан, Татарстан, Казан университеты тарихы буенча лекцияләр тыңладык. Энгельгард ис. обсерватория дә волонтерлар өчен үз ишекләрен ачты. Күк серләрен ачу зур шатлыклы вакыйга булды. Бер сүз белән, волонтерларның тик утырырга бөтенләй вакытлары юк.

Волонтер булуның тагын бик зур плюсы бар: дуслар табу. Кайбер иптәшләремнең фикерләрен сезнең игътибарга да тәкъдим итәм. Алар Универсиададан нәрсә көтә икән?

**Динара Сафина, Волейбол үзәге волонтеры:**

«Безнең гомуми һәм ориентацион тренинглар бетте инде. Һәр тренинг саен, яңа тәҗрибә тупладым. Волейбол серләренең нечкәлекләренә төшенәм. Моның белән әле өйрәнүләр тәмамланмады, алда безне функциональ тренинг көтә. Әзерлек дәвамында үземә яңа дуслар таптым. Вакытыбыз бик күңелле һәм күтәренке рухта уза. Универсиада чоры көтелмәгән вакыйгаларга бай булыр, дип ышанып калам».

**Раил Садретдинов, «Казан» ат спорты комплексы волонтеры:**

«Универсиада укулары башлангач, минем алда зур мөмкинлекләр ачылганын белдем. Әзерлек вакытында ни генә эшләмәдек без?! Аралашырга, бердәм булырга, стресска каршы торырга өйрәндек. Кулга каләм тотып, лекция язып утыру юк, бу – бик кызыклы тренинглар, аралашу. Быелгы Универсиададан мин кызыклы очрашулар, аралашу-танышулар көтәм. Универсиада минем өчен – зур тәҗрибә туплау. Казаныбызда узачак мондый зур вакыйгада һәркемнең өлеше булырга тиеш. Алга! Универсиадага!»

**Сәрия Миннебаева, Йөзү төрләре спорты үзәге волонтеры:**

«Универсиада – илебез өчен бик зур вакыйга... Мин аннан берничек тә читтә кала алмадым. Тест ярышлары үзебезнең ни дәрәҗәдә әзер икәнлегебезне күрсәтте. Әзерлекләр бу атнада да дәвам итәчәк. Универсиада һәркайсыбыз өчен дә югары мөмкинлекләр ача. Ә моны кулдан ычкындырырга ярамый. Бу уңайдан Казаныбыз да бик үзгәрде: чәчәкләргә, яшеллеккә күмелде».

Күк серләре

Әгәр обсерваториягә барырга уйласагыз, түбәндәге мәгълүмат нәкъ сезнең өчен!



**Акварида Дельтасы** яңгыры көньяк ярымшарда һәм төньяк ярымшарының тропикларында бик яхшы күренәчәк. Күзәтү өчен иң кулай вакыт 28-29 июль – кояш чыгуга бер-ике сәгать кала.

**Персиадалар** – елның иң якты метеорлы яңгырларының берсе. Быел (10-13 август) сәгатенә 50 метеор булыр дип көтелә, шулай ук кими торган айны Сатурн белән янәшә күрү мөмкинлеге дә булачак.

**Драконидалар**, башка яңгырлардан аермалы буларак, кичке якта (7 октябрь) яхшырак күренәләр.

**Орионидалар** метеор яңгырын 21 октябрьдә таң алдыннан карарга киңәш ителә, ләкин 2013 елда айның яктылыгы комачауларга мөмкин. Аның метеорлары бик якты һәм ай булганда да күреп булачак.

**Көньяк Тауридалар** яңгыры 25 сентябрьдән 25 ноябрьгә кадәр дәвам итәчәк. Ләкин метеорлар сирәк күренәчәк (сәгатенә – 7). Аларның саны аз булса да, бик якты булалар.

**Төньяк Тауридаларны** 12 октябрьдән алып, 2 декабрьгә кадәр күзәтергә мөмкин булачак. Иң күп метеорлы вакыт 12 ноябрьдә төнге 12 дән соң булачак.

Кызганычка каршы, тулы ай **Леонидалар** метеорлы яңгырының күз явын алырлык күренеше белән хозурланырга комачаулаячак. Ул – иң гаҗәп метеор яңгыры. Мисал өчен, 1966 елда 15 минут вакыт аралыгында минутына берничә мең метеор күзәткәннәр.

DARELFØNYN университет
Тираж 500
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.